Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР

19 август 2024 нче ел №28

Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Зур КУкмара авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (2018 елның 07 ноябрендәге 24 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 46 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 20 номерлы үзгәрешләр белән)(алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Айлык акчалата түләү нормативтан артмаган күләмдә түләнә: 11 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 14,12 айлык акчалата түләү 12 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 12,86 айлык акчалата бүләкләү.»;

1.2. 3 өлешнең 3.4 пунктчасында «(хезмәттәге катлаулылык, киеренкелек, югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. түбәндәге эчтәлектәге 3.1 булеген өстәргә:

«3.1. Дәүләт бүләге бирү яки бүләкләү өчен бер тапкыр бирелә торган акча

1. Муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, шулай ук бүләкләүгә яисә бүләк бирүгә тәкъдим ителгәннән соң муниципаль хезмәттән азат ителгән Россия Федерациясе гражданнарына (алга таба шулай ук – гражданнар) түбәндәге күләмдә бер тапкыр бирелә торган акча түләнә:

а) Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бүләкләнгәндә – биләгән вазыйфасы нигезендә 0,5 вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләмендә;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге белән бүләкләгәндә – биләгән вазыйфасы нигезендә 1,5 вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләмендә;

в) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан бүләкләнгәндә – бер вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләмендә;

г) Россия Федерациясенең Дәүләт бүләге белән бүләкләгәндә – ике вазыйфа оклады (акчалата бүләкләү) күләмендә.

2. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү бүләкләү яки бүләк бирү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты басылган көнгә, ә гражданнарга карата –аларны эштән азат итү турында хокукый акт чыккан көнгә билгеләнгән вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләменнән чыгып түләнә.

3. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күрсәтелгән затны җирле үзидарәнең тиешле органының хезмәткә түләү фонды акчалары хисабына бүләкләү яки бүләк бирү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты басылган көннән соң 30 көн эчендә күрсәтелгән зат муниципаль хезмәт вазыйфасын (муниципаль вазыйфаны) башкара торган яки башкарган җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәнәфиев